ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2023 г. Заинск № 862

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2022 елның 10 гыйнварындагы 02 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2022 елның 10 гыйнварындагы 02 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) "Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия әгъзалары составы" з нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта).

2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Юрист

Е.А. Улитина
3 79 17

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
18 10 2023 ел
862 номерлы карарына
3 нче кушымта

**САТЫП АЛУЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ БУЕНЧА КОМИССИЯ ӘГЪЗАЛАРЫ СОСТАВЫ**

1. Хәбибуллин Марат Мөдәрис улы – Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе *

2. Хаҗипов Ренат Мират улы – Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары **, ***

3. Бюджет оешмасы җитәкчесе (учреждение җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы зат яисә җаваплы зат (контракт идарәчесе) сатып алуларны гамәлгә ашыру комиссиясе утырышында катнашу өчен бюджет учреждениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән) – продукцияне алучы (товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр), муниципаль заказчы ****

* Хәбибуллин Марат Мөдәрис улы булмаганда (чираттагы ял, эш сәфәре, авыру һ.б.) комиссия рәисе вазыйфаларын тулы күләмдә Хаҗипов Ренат Мират улы – Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары башкара һәм аларны тиешенчә үтәү өчен җаваплылык тота.

** Хаҗипов Ренат Мират улы булмаган вакытка (чираттагы ял, эш сәфәре, авыру һ.б.) комиссия составына Шәйхиев Рәис Раиф улы - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе кертелә һәм ул комиссия әгъзасы бурычларын тулы күләмдә башкара, аларны тиешенчә үтәү өчен җаваплылык тота.

*** Хаҗипов Ренат Мират улы комиссия рәисе вазыйфаларын башкарган чорга комиссия составына Шәйхиев Рәис Раиф улы - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе кертелә һәм ул комиссия әгъзасы бурычларын тулы күләмдә башкара, аларны тиешенчә үтәү өчен җаваплылык тота.

**** *муниципаль заказ предметына карап, комиссия составына кертелә*

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘКТӘПЛӘРЕ ҺӘМ МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕЛӘРГӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ӨЧЕН ҮЗӘКЛӘШТЕРЕЛГӘН САТЫП АЛУЛАРНЫ ОЕШТЫРУНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ БУЕНЧА КОМИССИЯ ӘГЪЗАЛАРЫ СОСТАВЫ**

1. Хәбибуллин Марат Мөдәрис улы – Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе *

2. Хаҗипов Ренат Мират улы – Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары **, ***

3. Никишина Алина Владимировна – «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлегенең сатып алулар буенча әйдәп баручы белгеч – мәктәп һәм мәктәпкәчә учреждениеләр муниципаль заказчыларыннан вәкил ****

* Хәбибуллин Марат Мөдәрис улы булмаганда (чираттагы ял, эш сәфәре, авыру һ.б.) комиссия рәисе вазыйфаларын тулы күләмдә Хаҗипов Ренат Мират улы – Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары башкара һәм аларны тиешенчә үтәү өчен җаваплылык тота.

** Хаҗипов Ренат Мират улы булмаган вакытка (чираттагы ял, эш сәфәре, авыру һ.б.) комиссия составына Шәйхиев Рәис Раиф улы - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе кертелә һәм ул комиссия әгъзасы бурычларын тулы күләмдә башкара, аларны тиешенчә үтәү өчен җаваплылык тота.

*** Хаҗипов Ренат Мират улы комиссия рәисе вазыйфаларын башкарган чорга комиссия составына Шәйхиев Рәис Раиф улы - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисе кертелә һәм ул комиссия әгъзасы бурычларын тулы күләмдә башкара, аларны тиешенчә үтәү өчен җаваплылык тота.

***** Никишина Алина Владимировна булмаганда (командировкада, ялда булу, авыру сәбәпле), комиссия составына мәгариф идарәсенең үзәкләштерелгән хисап бүлеге баш белгече Журавлева Юлия Сергеевна - «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге баш белгече кертелә һәм бу эш өчен җаваплылыкны тулы күләмдә үз өстенә ала.